ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КЕРЛИГАЧСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Советская ул., дом 33а, село Керлигач,
Лениногорский район, 423293

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КИРЛЕГӘЧ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 33а йорт, Кирлегәч авылы,
Лениногорск районы, 423293

Тел./факс: (8-85595) 3-10-10, Kerliq.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17 октябрь 2024 ел. № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2016 елның 6 апрелендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 маддәсе нигезендә, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында»Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указының 8 пункты белән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2016 елның 6 апрелендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган

шəхси кызыксыну барлыкка килү турында хəбəр итү тəртибенə түбəндəге үзгəрешне кертергə:

6, 7 пунктларны төшереп калдырырга;

8 пунктта «яллаучыга яисə яллаучы вəкиленə, Лениногорск муниципаль районы башлыгына, муниципаль районның вəкиллекле органы рəисенə» сүзлəрен «авыл җирлеге башлыгына» сүзлəренə алмаштырырга»;

9 пунктта «муниципаль районның вəкиллекле органы рəисе, яллаучы яисə яллаучы вəкиле» сүзлəрен төшереп калдырырга»;

10, 11 пунктларда «муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вəкиллекле органы рəисе яки яллаучы» сүзлəрен «авыл җирлеге башлыгы» сүзлəренə алмаштырырга»;

2. Әлеге карарны җирлекнең түбəндəге адресы буенча урнашкан мəгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Кирлегəч авылы, Совет урамы, 33А йорты, Лениногорск муниципаль районының рəсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һəм Татарстан Республикасының рəсми хокукый мəгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Кирлегəч авыл җирлеге” муниципаль
берəмлеге башлыгы С.Р.Сəлахова